| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ТИМЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТИМӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2022 елның «18» августы № 17

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 9 июлендәге 22 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (2017 елның 6 июлендәге 17 номерлы редакциядә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Лениногорск шәһәр прокуратурасының 2022 елның 16 августындагы 02-08-03 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Тимәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану буенча өстәмә нигезләр турында» 2014 елның 9 июлендәге 22 номерлы карарына (2017 елның 6 июлендәге 17 номерлы редакциядә) үзгәрешне кертергә:

Совет карарының преамбуласында «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 2010 елның 19 августындагы ЯК-7-8/393@ номерлы «Недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләтүгә өметсез дип табылган недоимканы һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычны юкка чыгару тәртибен раслау турында» боерыгы» сүзләрен «Россия Федераль салым хезмәтенең 2019 елның 2 апрелендәге ММВ-7-8/164@ номерлы (2021 елның 13 декабрендәге ред.) «Пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча түләүгә өметсез дип танылган недоимканы һәм бурычларны бетерү тәртибен һәм недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеген раслау турында» боерыгы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71Д (җирле үзидарә бинасы), Киров урамы, 26 (мәдәният йорты), нефтьүткәргечләр урамы, 20 (Ромашкино РНУ утырышлар залы), Киров урамы, 1А («Ласточка» балалар бакчасы), Лесная урамы, 20, Лесная урамы,33 адреслары буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.М.Сираев